**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«_27_» ___12__2024 ел **№** 46 Урыссу штб

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының 18.05.2018 елның № 10 санлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 елның № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында"гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"гы 25.09.2024 елның № 829 санлы карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының 18.05.2018 елның №10 санлы карары белән расланган депутатларга, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 бүлегенең 1 пунктында "12 688" саннарын "13 323" саннарына алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 1 өлешендәге 6 пунктында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 1 пунктындагы 6 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталы «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин